“Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен Әлмәт интернат-мәктәбе”
дәүләт бюджет гомуми белем учреждениесе

Педагогик
киңәшмә утырышында каралды
“29” август 2022ел. № 1
Интернат мәктәбе директоры
_______________Л.Р.Мартынова
Боерык белән кертелде № 98-0
“31 ”августа 2022 ел

**2нче ГОМУМБЕЛЕМБИРҮ** сыйныфы өчен
**уку предметы буенча туган (ТАТАР) ӘДӘБИ УКУДАН**
**эш программасы**
Атнага **0.5** сәгать**,** елга **17** сәгать

Төзүчесе:
**татар теле һәм әдәбият укытучысы Мөхәммәтҗанова Л.Ф.**

Килешенгән:
Директор урынбасары________И.Б.Шарифуллина

МБ утырышында каралды, беркетмә№ 1 “ 26 ”август 2022 ел
МБ җитәкчесе ___________Л.Ю. Сайфутдинова

Әлмәт 2022 ел

**Уку предметы буенча 2 нче сыйныфта укудан эш программасына аңлатмалы язу.**

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:
1. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы Законы (21.12.2012, №273-ФЗ)
2. Россия Федерациясенең “Россия Федерациясе халык телләре турында”гы Законы (25.10.1991, №1807-1, ред.12.03.2014)
3. Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгы боерыгы 19.12.2014 №1598
4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Инвалид балаларны өйдә тәрбияләү һәм укыту тәртибе һәм инвалидларның белем алу мөмкинлеген тәэмин итү буенча социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чаралары турында" 16.06. 2008 ел, 401 нче карары.
5. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында”гы Законы (22.07.2013, № 68-ЗРТ)
6. “Татарстан Республикасының халык телләре турында” Законы (8.07.1992, №1560-XII; ред. 12.06.2014№53-ЗРТ)
7. Авторлык программасы: Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы(1 — 11 нче сыйныфлар) /Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева, Казан:2018
8. Әлмәт интернат мәктәбендә дисциплина, предмет, уку курсларының эш программалары раслануы, эшләү тәртибе, структура нигезләмәсе 31.08.22 № 98-О.
9. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына программасы.
10. Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына базислы уку-укыту планы.
11.Татарстан Республикасы Әлмәт-интернат мәктәбенең 2022-2023 нче уку елына эш программасы турында нигезләмә (локальный акт).

Рус телле балаларга укуны укытуның төп максаты: укучыларны татарча аралашырга өйрәтү,татар теленең орфоэпик, орфографик.лексик, грамматик нигезләрен системалы рәвештә үзләштерү,телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.
Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:
1) татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;
2) татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
3) программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
4) карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
5) татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;
6) татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкә¬сендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныш¬тыруны дәвам итү;
7) халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

**Уку елы башында белергә тиешле белемнәр:**

**I. Сөйләшү.**

Диалогик сөйләм.

1-сыйныфта дәрес вакытының 70-80% ын сөйләшергә өйрәтү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

Монологик сөйләм:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;
- өйрәнелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**II. Ишетеп аңлау.**

Аралашу өчен төп шартларның берсе - әңгәмәдәшләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 1-сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда куллана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**III. Уку.**

Уку эшчәнлеге буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар әлифбасына гына хас хәрефләрне дөрес уку, авазларны дөрес әйтә белү;
- транскрипция билгеләрен укый һәм куллана белү күнекмәләрен формалаштыру;
- интерференция күренешеннән котылу өчен, рус теленнән кергән сүзләрдә һәм татар теленең үз сүзләрендә бер үк хәрефнең төрле авазлар белдерүен аңлап аера белү;
- сәнгатьле дөрес уку күнекмәләрен формалаштыру;
- уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр өйрәнү.

**IV. Язу.**

- 1-сыйныфта язуга өйрәтүнең төп максаты – татар әлифбасы хәрефләрен, программага кергән сүзләрне дөрес язарга өйрәнү;
- иптәшенә яки әниенә записка язу, төрле бәйрәмнәр белән котлау, уенга чакыру язу, үзең турында кечкенә белешмә яза белү күнекмәләрен булдыру;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен формалаштыру.

**Уку елы азагында белергә тиешле белемнәр:**

*Грамматик минимум:*

1. *Нәрсә? кайда? кая? кайдан? нинди? ничек? кайчан?* сорауларына җавап бирә белү.
2. Исемнәрнең сораулары.
3. Исемнәрнең 1, 2, 3 нче затта берлектә тартым белән төрләнеше.
4. Хәзерге заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.

5. Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасында зат-сан белән төрләнеше.
6. Үткән заман хикәя фигыль.
7. Сүзнең тамыры, кушымчасы.
8. Үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнеше.
9. Сингармонизм законы.
10. 11дән 20гә кадәрге саннар.
11. *Сабын белән юына* төзелмәсе.
12. Берлек һәм күплек сандагы исемнәрне төшем килешендә куллану.
13. Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы.
14. О, ө хәрефләренең беренче иҗектә язылуы.
15. *Чөнки* теркәгечен сөйләмдә куллану.
16. *Һәм* теркәгечен сөйләмдә куллану.
17. *Ә* теркәгечен сөйләмдә куллану.

*Орфоэпик һәм орфографик минимум:*

1. Татар алфавиты һәм аны өйрәнү, яттан белү.
2. Сузык авзлар.
3. Тартык авазлар.
4. Сүзләрне иҗекләргә бүлү.
5. Сүз басымы.
6. Аралашу өчен бирелгән темаларга караган сүзләрнең дөрес әйтелешенә ирешү.
7. Исемнәрнең берлек, күплек сан формаларын аеру.
8. Җөмлә ахырында тыныш билгеләрен интонациягә бәйле рәвештә кую.
9. Орфоэпик һәм орфографик күнекмәләрне камилләштерү.

*Тыңлап аңлау:*

- нормаль темп белән әйтелгәнне ишетү аша мәгънәне аңлау, аңлаган турында фикер йөртү, аралашуда куллана белү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аера белү;
- җөмләләрне тыңлап, сүз санын билгеләү.

*Диалогик сөйләм:*

Дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү; аралашу өчен бирелгән темалар буенча әңгәмә кору.

Уку:

- аңлап, дөрес итеп уку;
- тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү;
- өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү.

Язу:

- аерым җөмләләрне, кечкенә текстларны үзгәрешсез дөрес итеп күчереп язу;

- матур язу күнегүләре;
- бәйрәмнәр белән котлап, котлау кәгазьләре язу;
- сүзлек диктанты язу.

**Әлмәт интернат мәктәбендә 2 нче гомум белем бирү сыйныфында уку әлеге бүлекләр буенча укытыла:**

1. Яңа уку елы белән! (8 сәг.)
2. Ел фасыллары. Көз.( 9 сәг)
3. Чисталык һәм сәламәтлек (2 сәг.)
4. Безнең гаилә (4 сәг.)
5. Кыш (5 сәг.)
6. Яз (2 сәг.)
7. Татарстан – туган җирем (2 сәг.)
8. Мин шәһәрдә һәм авылда (3 сәг.)
9. Кибеттә (2 сәг.)
10. Җәй (1 сәг.)

**Мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары:**

1. Дәреслек: 2- сыйныф “Татар теле һәм уку китабы” Р.З.Хәйдәрова,  Г.М. Әхмәтҗанова, Л.А.Гиниятуллина     2013 ел
2. Татар теле дәресләре.2 нче сыйныф. Рус телендә сөйләшүче балалар белән эшләүче укытучылар өчен кулланма. Р.З.Хәйдарова, Мәгариф,2009 ел.
3. “Гомуми урта белем бирү мәктәпләренең 2 нче сыйныфында укучы рус телле балаларга татар теленнән контроль эшләр”, Р.З.Хәйдәрова, Яр Чаллы 2010 ел
4. З. Н. Хәбибуллина, К. Х. Фәйзрахманова. Татар теленнән мөстәкыйль эшләр. К.: “Мәгариф”, 2008 ел.
5. Р.Р. Нигъмәтуллина.Татарча да яхшы бел. Контроль тестлар һәм текстлар. К.:  “Мәгариф”, 2006 ел.
6. Р. Р. Нигъмәтуллина. Татар теле өйрәнүчеләргә кагыйдәләр һә мкүнегүләр. К.: “Мәгариф”, 2005 ел.
7. «Фән һәм мәктәп», «Мәгариф»  журналлары, “Мәгърифәт”, “Ачык дәрес” газеталары.

| Дәрес № | Дәрес темасы | Лексика | Укучыларның эшчәнлеге | Число План | Число Факт |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | С новым учебным годом!<br><br>Яңа уку елы белән! | Исәнләшү, саубуллашу лексикасы. Уку язу әсбаплары исемнәре | Исемнәрнең I, II, III затта берлек санда тартым белән төрләнешен белү | 5.09 | |
| 2 | Первое сентября – большой праздник.<br><br>Беренче сентябрь – зур бәйрәм. Мин – дәрестә. | 1-дәрес лексикасы | Хәзерге заман хикәя фигыльнең III зат юклык формасын белү | 12.09 | |
| 3 | О себе.<br><br>Үзем турында. | хикәя, күнегү, өтер, нокта | Исемнәрнең тартым белән төрләнешен аңлау | 19.09 | |
| 4 | Текст “В нашем классе”. Использование глагола изъявительного наклонения настоящего времени в тексте.<br><br>“Безнең сыйныфта” тексты. Текстта хәзерге заман хикәя фигыль. | 3-4 дәресләр лексикасы; ялкау, тәнәфес, ача, яба | Текстның эчтәлеген белү | 26.09 | |
| 5 | Б.Рахмат “В школе”.<br><br>Б.Рәхмәт.”Мәктәпкә” | юл, дәү, зур, икеле, белә, өйрәтә | Сәнгатьле итеп уку | 3.10 | |
| 6 | В школе большой праздник.<br><br>Мәктәптә зур бәйрәм. | дәвам итә, тәрҗемә итә | Җөмләдә сүзләргә сорау куярга өйрәнү | 10.10 | |
| 7 | Какая бывает осень?<br><br>Көз нинди була? | көз көне, төн кыска, озын, яфрак коела, җылы як, исә | ө, о хәрефләренең дөрес язылышын белү | 17.10 | |
| 8 | Текст “На базаре”.<br><br>“Базарда” тексты. | сатып ала, эре, бай, түгәрәк | *Кая? Кайда? Кайдан?* сорауларына җавап бирү | 24.10 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Овощной магазин.<br><br>Яшелчә кибете. | яшелчә исемнәре | Яшелчә исемнәрен белү | 7.11 | |
| 10 | Песня Г.Гараева “Осень и дети”.<br><br>Г.Гәрәева. “Көз һәм балалар” җыры. | алтын көз, суык, салкын | Җырны яттан белү | 14.11 | |
| 11 | Режим дня.<br><br>Көндәлек режим язу. | кош, төзәт, йокла,яшә, уйна, аша, җырла, сөйлә | Сингармонизм законын белү | 21.11 | |
| 12 | Я умею говорить время.<br><br>Мин вакытны әйтә беләм. | сәгать, дәрес әзерли, сәгать ничәдә, сәгать икедә,йокы | Сәгать икедә структурасын сөйләмдә куллану | 28.11 | |
| 13 | М.Джалиль “Часы”. Что я сегодня делал?<br><br>М.Җәлил. “Сәгать”.<br>Мин бүген нишләдем? | Алдагы дәреснең лексикасы. сәгать ничәдә, тор, кара, сикер, кайт, дәрес әзерлә | Шигырьне сәнгатьле итеп уку<br>Үткән заман хикәя фигыльнең зат-сан белән төрләнешен белү | 5.12 | |
| 14 | Рассказ “Алсу – аккуратная девочка”.<br><br>“Алсу – пөхтә кыз” хикәясе. | тагын, сөртә, иртән, пөхтә, көндез, йомшак | *Сабын белән юына, щетка белән теш чистарта* структураларын сөйләмдә куллану | 12.12 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Рассказ “Умный мальчик”. Около врача.<br><br>“Акыллы малай” хикәясе. Табиб янында. | акыллы, урын җыя<br>дару, җылы сөт кирәк (-ме), температураңны кара, авырта, үлчи | Хикәянең эчтәлеген белү<br>20-100гә кадәр саннарны белү | 19.12 | |
| 16 | А.Бикчантаева “Бабушка”.<br><br>Ә.Бикчәнтаева. “Дәү әнием.” | үстерә, озак, кадерле | Сәнгатьле итеп уку | 26.12 | |
| 17 | Ш.Маннур “Люблю”.<br><br>Ш.Маннур.”Яратам”. | әне, бакча, өй, сеңел, иптәш | Берлек һәм күплек сандагы исемнәрне төшем килешендә куллану | 9.01 | |
| 18 | Рассказ “Мама готовит стол”.<br><br>“Әни табын әзерли”хикәясе. | тоз, сөт, уң як, чәйнек, шикәр, сул як, табын | Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 16.01 | |
| 19 | Работа над текстом “Выходной день”.<br><br>“Ял көне” тексты өстендә эш. | кичке аш, иртән, кич, ял көне, көндез, кайчан? | Текстның эчтәлеген белү | 23.01 | |
| 20 | Рассказ “Зима идет”, “Мы помогаем птицам”.<br><br>“Кыш килә” хикәясе.<br>“Без кошларга булышабыз” хикәясе. | кыш айлары, бөтен, кала тукран, авыр, песнәк, ала карга | Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 30.01 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 21 | С.Сабирова “Песня Деда Мороза”.<br><br>С.Сабирова. “Кыш бабай җыры”. | таныш дус, яңа ел, нарат, бәхет тели | Яңа елга котлау тексты язу | 6.02 | |
| 22 | Текст “Праздник ёлки”.<br><br>“Чыршы бәйрәме” тексты. | чыршы бәйрәме, була, бию, өченче | Тәртип саннарын сөйләмдә куллану. Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 13.02 | |
| 23 | Мы на гору идём. Рассказ “На каникулах”.<br><br>Без тауга барабыз. “Каникулда” хикәясе. | кәшәкә таягы<br>якын, әбәкле уены | Ә теркәгечен сөйләмдә куллану<br>Үткән заман хикәя фигыльне сөйләмдә куллану. Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 20.02 | |
| 24 | Рассказ “На горе”.<br><br>“Тауда” хикәясе. | шатланды, кар бабай | *Чөнки* теркәгечен җөмлә эчендә куллану. *Һәм* теркәгечен сөйләмдә куллану. Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 27.02 | |
| 25 | Рассказ “Весна”.<br><br>“Яз” хикәясе. | ямьле, боз китә | Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 6.03 | |
| 26 | 8 Марта – праздник мам.<br><br>8 нче Март - әниләр бәйрәме. | 8 нче Март бәйрәме, бүләк | 8 нче Март бәйрәме белән котлау язу | 13.03 | |
| 27 | Рассказ “Родной край”. Где я живу?<br><br>“Туган ягым” хикәясе. Мин кайда яшим? | аз, кыр, туган җир, Агыйдел, куе, Идел, поши | Хикәяне сәнгатьле итеп уку.<br>Мин кайда яшим? соравына җавап бирү | 20.03 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 28 | А.Рашитов “Солнечная страна”.<br><br>Ә.Рәшитов. “Кояшлы ил”. | район, шәһәр, шигырь | Сәнгатьле итеп уку | 10.04 | |
| 29 | Текст “Казанский гость”.<br><br>“Казан кунагы” тексты. | башкала, Казан турында, кунак, ерак, монда, таныш | Текстның эчтәлеген белү | 17.04 | |
| 30 | Где я живу? Олег – воспитанный мальчик.<br><br>Мин кайда яшим?<br>Олег – тәрбияле малай. | Татарстан шәһәрләре исемнәре. рәхимле, урын | Татарстан шәһәрләре исемнәрен белү. Текстның эчтәлеген белү | 24.04 | |
| 31 | Текст “На дороге”.<br><br>“Юлда” тексты. | тукталыш, туктый, юл аша, яна, саклый, елмая, ут | Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 1.05 | |
| 32 | Моя одежда. В магазине одежды.<br><br>Минем киемнәрем.<br>Киемнәр кибетендә. | алъяпкыч, түбәтәй, кием, киемнәр кибете | Тема бенча лексиканы белү | 8.05 | |
| 33 | Повторение. Кабатлау. | | | 15.05<br>22.05 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 34 | Рассказ “Красивая одежда”. Давай вместе играть. “В магазине”.<br><br>“Матур киемнәр” хикәясе. Әйдә бергә уйныйбыз. “Кибеттә” | сатып ала, киеп карый, түли, сайлый<br>кием –салым исемнәре; арзан, кыйбат, сум, кирәк, килешә тимә, туган көнең белән<br>риза, риза түгел | Тема бенча лексиканы белү.<br>Хикәяне сәнгатьле итеп уку | 19.05 | |

**Эш программасына үзгәрешләр кертү бите**

| Класс | Теманың исеме | План буенча уздыру вакыты | Үзгәреш кертүнең сәбәбе | Факт буенча уздыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |